ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 июль 2016 ел № 3717

2016-2017 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Муниципаль заказ дирекциясе» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга, шәһәр Уставының 41 маддәсенә, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карарына, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карарына туры китереп

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2016-2017 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Муниципаль заказ дирекциясе» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2016 елның 21 июлендәге
3717 нче карарына
кушымта

2016-2017 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Муниципаль заказ дирекциясе» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. | Сатып алулар өлкәсендәге законнар буенча юридик консультация бирү | | 2087,22 |
| 2. | Сатып алулар өлкәсендә белгечләрне укыту (башлангыч дәрәҗә) | | 3539,22 |
| 3. | Сатып алулар өлкәсендә белгечләрне укыту (уртача дәрәҗә) | | 5422,11 |
| 4. | Сатып алулар өлкәсендә белгечләрне укыту (белгеч дәрәҗәсе) | | 11878,45 |
| 5. | Документлар пакеты әзерләү һәм ЭТПда аккредитация алу буенча техник ярдәм күрсәтү | | 5073,03 |
| 6. | Белгечләрне ЭТПда эшләү өчен программалар белән тәэмин итү эшенә укыту (тәэмин итүченең шәхси кабинеты) | | 3146,32 |
| 7. | ТР сатулар (торги) турында мәгълүмат мониторингы (эшчәнлек өлкәсе буенча тендерлар сайлап алу) | | 3645,46 |
| 8. | Электрон аукцион буенча ярдәм күрсәтү (тәэмин итүчеләр өчен) | | 5045,10 |
| 9. | Сатуларда (торги) катнашуга заявка әзерләү (тәэмин итүчеләр өчен) | | 5210,10 |
| 10. | РФ Федераль монополиягә каршы хезмәткә шикаять әзерләү | | 5125,27 |
| 11. | РФ Федераль монополиягә каршы хезмәткә, судларда мәнфәгатьләр җиткерү | | 17403,42 |
| 12. | Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау килешүләре төзү хокукына ачык аукцион үткәрү | | 5074,85 |
| 13. | Аукцион процедурасы үткәрү | | 804,85 |
| 14. | Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау килешүләре төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (1 лот) | | 9000,74 |
| 15. | Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау килешүләре төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (2-6 лотлар) | | 12380,52 |
| 16. | Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау килешүләре төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (6 дан башлап һәм аннан күбрәк лот) | | 15179,79 |
| 17. | Конкурс яки аукцион үткәрү юлы белән тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү | | 11720,28 |
| 18. | Автономияле учреждениеләрнең ихтыяҗлары өчен сатып алу эшчәнлеге буенча юридик ярдәм (Н(М)Ц <100 000,00 сум) | | 2927,32 |
| 19. | Автономияле учреждениеләрнең ихтыяҗлары өчен сатып алу эшчәнлеге буенча юридик ярдәм (Н(М)Ц ≥ 100 000,00 сум) | | 3926,75 |
| 20. | Автономияле учреждениеләрнең ихтыяҗлары өчен капиталь һәм техник ремонт өлкәсендә сатып алу эшчәнлеге буенча юридик ярдәм | | 6831,45 |
| 21. | Сатып алу эшчәнлеге буенча юридик ярдәм (223-ФЗ санлы Федераль закон буенча) | | 7863,71 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Г.К. Әхмәтова